**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә дәүләт бүләкләрен бирү системасын камилләштерү, иҗади эшчәнлекне стимуллаштыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы, 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы, 2011 елның 7 сентябрендәге ПУ-549 номерлы һәм 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), 1 пункттагы икенче абзацта «һәркайсы 300 мең сум» сүзләрен «һәркайсы биш йөз мең сум» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указда каралган чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2014 ел, 15 март
№ ПУ-275